РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**РУКОВОДИТЕЛЬ БОЛЬШЕМЕТЕСКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Ф.Хусни, 56 А, село Большие Метески, 422082
тел.: (884360) 54-4-40 (факс)

E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ОКПО 94318062 ОГРН1061675010430

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**
Ф.Хөсни урамы, 56 А, Олы Мәтәскә авылы, 422082
тел. (884360) 54-4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ИНН КПП 1619004411/161901001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№14** **13.08.2020г.**

Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Олы Мәтәскә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын каран, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Олы Мәтәскә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

-Олы Мәтәскә авылы Ф.Хөсни урамы 56А йорт бинасында мәгълүмат стенды;
- Югары Мәтәскә авылы Үзәк урамы 17А йорт бинасында мәгълүмат стенды;
- Ямбулат авылы М.Ногуманов урамы 18 йорт бинасында мәгълүмат стенды;
- Лесной бистәсе Татарстан урамы 18 йорт бинасында мәгълүмат стенды;

- Тәмте - Мәтәскә  авылы  Тау асты  урамы 56А йорт бинасында мәгълүмат стенды;

2. Олы Мәтәскә  авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә  авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 июль №3  карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Олы Мәтәскә  авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча :  56А йорт, Ф.Хөсни урамы , Олы Мәтәскә  авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Олы Мәтәскә авыл
җирлеге башлыгы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА БОЛЬШЕМЕТЕСКИНСКОЕ
БОЛЬШЕМЕТЕСКИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1619004411

М.А.Валиуллин